ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.04.2022 п.г.т.Алексеевское № 115

**«Алкоголь продукциясенең законсыз әйләнешен ачыклау һәм бетерү буенча ведомствоара комиссия төзү турында» Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 07 декабрендәге 434 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә югары сыйфатлы алкоголь продукциясен җитештерү һәм сату күләмнәрен арттыру чаралары турында» 2004 елның 16 гыйнварындагы 10 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә һәм югары сыйфатлы алкоголь продукциясен җитештерү һәм сату күләмнәрен арттыру, аның ассортиментын киңәйтү, шулай ук эчке кулланучылар базарыннан фальсификацияләнгән алкоголь продукциясен кысрыклап чыгару максатларында

**карар бирәм**:

1. Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 07 декабрендәге 434 номерлы карарына 1 нче кушымтада түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

«Васильев А.Д. – Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары, комиссия әгъзасы»

сүзләрен түбәндәге сүзләр белән алмаштырырга:

«Язынин Р.С. – Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары, комиссия әгъзасы»;

«Ищенко С.А. – РФ Федераль салым хезмәтенең ТР буенча 12 нче районара инспекциясе баш дәүләт салым инспекторы (килешү буенча), комиссия әгъзасы»

сүзләрен түбәндәге сүзләр белән алмаштырырга:

«Газизов А.Т. – Федераль салым хезмәтенең ТР буенча 12 нче районара инспекциясе җитәкчесе (килешү буенча), комиссия әгъзасы».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе О.А.Гайнуллинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **М.Р.Гайсин**